ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДАНАУРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
422951 Республика Татарстан,
Чистопольский район
д.Данауровка ул. Центральная д.20А

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ДАНАУРОВКА АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422951, Татарстан Республикасы
Чистай районы, Данауровка авылы
Узек ур., 20А

тел.884342 5-71-38, e-mail:Dnr.Ctp@tatar.ru

Постановление　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　Карар

2019 елның 24 декабре　　　　　　　　　　　　　　　　№ 07

Чистай муниципаль районының
Данауровка авыл җирлеге гражданнарының
үзара салым акчаларын җыю Тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән, Чистай муниципаль районының «Данауровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Чистай муниципаль районының Данауровка авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыеннарында кабул ителгән карарларны гамәлгә ашыру максатларында (Данауровка авылы гражданнар җыенының 2019 елның «23» ноябрендәге 1 номерлы карары, Галактионово авылы гражданнар җыенының 2019 елның «26» ноябрендәге 2 номерлы карары) Чистай муниципаль районы Данауровка авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Чистай муниципаль районының Данауровка авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю буенча тәкъдим ителгән Тәртипне расларга.
2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендлары аша игълан итәргә һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында http:/chistopol.tatarstan.ru урнаштырырга.

Данауровка авыл
җирлеге башлыгы　　　　　　　　　　　　　　　　　　　В.К.Садретдинова

Чистай муниципаль районы
Данауровка авыл җирлегенең
Башкарма комитеты тарафыннан
2019 елның 24 декабре 7 номерлы
карары белән расланды

Чистай муниципаль районының
Данауровка авыл җирлеге гражданнарының
үзара салым акчаларын җыю Тәртибе

1. Әлеге Тәртип Чистай муниципаль районының Данауровка авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчалары 2020 елның 10 мартына кадәр Чистай муниципаль районының Данауровка авыл җирлеге территориясендә теркәлгән, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, 1 төркем инвалидларыннан тыш (түләүдән азат ителгән гражданнарның категорияләрен күрсәтергә), 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан, аларның җыенда катнашуларына һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләренә карамастан, түләнә.

3. Бер тапкыр түләү турында хәбәр итү кәгазе (хәбәрнамә) бланкы, Чистай муниципаль районы Данауровка авыл җирлеге торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмат стендларында урнаштырып халыкка җиткерү юлы белән яисә имза куеп тапшыру, яки почта элемтәсе аша җиткерелә.

Хәбәрнамәдә гражданнарның үзара салым акчасын күчерү реквизитлары, бер тапкыр түләнә торган түләү суммасы, тулы күләмдә яисә киметелгән күләмдә, аны түләү срогы күрсәтелергә тиеш.

4. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Чистай муниципаль районының «Данауровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең шәхси счетына керә.

5. Гражданнар тарафыннан түләү физик затлар кушуы буенча исәп-хисап ясау хокукына ия булган оешмалар аша, почта күчерүләре (исәп-хисап оешмаларын) Чистай муниципаль районы Данауровка авыл җирлеге башкарма комитеты кассасы аша, яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша (сылтама буенча), акча күчерү юлы белән башкарыла https://uslugi.tatarstan.ru/.

6. Түләү фактын раслау булып килү касса ордеры, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслаучы башка документлар тора.

7. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән гражданнарның үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

ТР Чистай муниципаль районының
Данауровка авыл җирлеге
гражданнарының үзара салым
акчаларын җыю Тәртибенә
кушымта

ТР Чистай муниципаль районы Данауровка авыл җирлеге муниципаль берәмлеге бюджетына үзара салым акчаларын бер тапкыр түләү турында

ХӘБӘР (ХӘБӘРНАМӘ) № _______________

Түләүченең Ф. И. атасының исеме
___________________________________________________________________________

Адрес: _____________________________________________________________

_________________________________________________________________ нигезендә

Сезгә, түбәндәге реквизитлар буенча: ________________ срогына кадәр, __________ суммада, чараларны тормышка ашыру өчен бер тапкыр түләү түләргә кирәк.

түбәндәге реквизитлар буенча:__________________________________________________

Алучы Банк БИК ______________________________________

Сч. № __________________________________

Алучы Сч. № _________________________________________

ИНН ________________________________________

КПП __________________________________________

КБК _______________ ОКАТО ___________________

Түләү билгеләү ______________________________________________________________

Җитәкче _________________ ________________________________________

М.П. (имза) (тулы имза)

- - - - - - - - - - - - - - - - - кисү өчен - - - - - - - - - - - - - - -

хәбәр (хәбәрнамә) № _____

________________ сум күләмендә

Түләүченең Ф. И. атасының исеме __________________________________________

Адрес: __________________________________________________________________________

Алды «__» _______________ 20__ ел. ______________________________________

(түләүче имзасы)

Искәрмә. Корешокның өзелгән өлеше ____________ авыл җирлеге Башкарма комитетында тутырыла һәм кала.